**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

27.11.2025 № 435

**Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләр буенча эш төркеме төзү турында**

Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләр буенча нәтиҗәле үзара эшчәнлеген тәэмин итү максатларында:

1. Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләр буенча эш төркеме төзергә.

2. Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләр буенча эш төркеме турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның « 27 » ноябрендәге
435 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләр буенча эш төркеме турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләр буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) – Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләр буенча нәтиҗәле үзара эшчәнлеген тәэмин итү максатларында төзелгән даими эшли торган киңәшмә органы.

2. Эш төркеме Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

II. Эш төркеменең төп бурычлары

3. Эш төркеменең төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләрне карап тикшерү һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм оешмалар өчен аларның үзара эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр эшләү;

б) күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую өлкәсендә норматив хокукый җайга салуның тулылыгын һәм нәтиҗәлелеген анализлау һәм мондый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

4. Эш төркеме үз алдында торган бурычларны үтәү максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары, оешмалардан законнар нигезендә эш төркеме эшчәнлеге даирәсенә керә торган мәсьәләләр буенча кирәкле мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга;

б) үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары, оешмалар вәкилләрен һәм кызыксыну белдергән башка затларны чакырырга;

в) эш төркеме эшчәнлегенә эш төркеме эшчәнлеге даирәсенә керә торган мәсьәләләрдә махсус белеме булган белгечләрне җәлеп итәргә.

## III. Эш төркеме составы

5. Эш төркеме составы Татарстан Республикасы Рәисенең боерыгы нигезендә раслана.

6. Эш төркеме составына аның җитәкчесе, җитәкчесенең урынбасары, секретаре һәм әгъзалары керә.

7. Эш төркеменең җитәкчесе Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе була.

8. Эш төркеме җитәкчесе:

а) эш төркеме эшчәнлегенә җитәкчелек итә, эш төркеме утырышларына куелган мәсьәләләр исемлеген, аларны карап тикшерү вакытын һәм тәртибен билгели;

б) эш төркеме җитәкчесе урынбасары белән әгъзалары арасында вәкаләтләрне (йөкләмәләрне) бүлә;

в) эш төркеме утырышлары көн тәртибен, аларны уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

г) эш төркеме утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларга имза куя.

9. Эш төркеме секретаре:

а) эш төркеме утырышларында шәхсән катнаша;

б) утырыш буласы көнгә кимендә өч эш көне кала утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында эш төркеме әгъзаларына хәбәр итә;

в) эш төркеме утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларны әзерли.

10. Эш төркеме әгъзалары:

а) эш төркеме утырышларында шәхсән катнаша;

б) эш төркеме эшчәнлеге даирәсенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куя;

в) эш төркеме карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

## IV. Эш төркеме эшчәнлеген оештыру

11. Эш төркеме утырышлары ихтыяҗ туган саен, әмма кимендә кварталга бер тапкыр уздырыла.

12. Эш төркеме утырышларын җитәкче алып бара. Эш төркеме җитәкчесе вакытлыча эш урынында булмаганда, аның вазыйфаларын эш төркеме җитәкчесе урынбасары башкара.

13. Эш төркеме утырышлары, анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, эшчәнлек алып барырга хокуклы дип санала.

14. Эш төркеме карарлары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта, эш төркеме утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

15. Эш төркеме карарын эш төркеме секретаре әзерли һәм ул беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

16. Эш төркеме утырышы беркетмәсе эш төркеме утырышында рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм имзаланган көннән биш эш көненнән дә соңармыйча, эш төркеме әгъзаларына юллана.

17. Эш төркеме карарлары күрсәтмә характерында була.

18. Эш төркеме эшчәнлеген оештыру-техник яктан, документлар, мәгълүмат белән һәм башкача тәэмин итүне Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе башкара.

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «27» ноябрендәге
435 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасында күчемсез милек объектларына дәүләт кадастр бәясе кую белән бәйле мәсьәләләр буенча эш төркеме составы**

| | |
|---|---|
| Мирзакриев Рөстәм Рәүф улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, эш төркеме җитәкчесе |
| Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры, эш төркеме җитәкчесе урынбасары |
| Габдрахманов Алмаз Фәрит улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җитәкчесе урынбасары – Департаментның җир-мөлкәт мөнәсәбәтләрен координацияләү һәм үстерү бүлеге мөдире, эш төркеме секретаре |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, секретариат җитәкчесе урынбасары |
| Анфимова Алла Леонидовна | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Нәбиуллина Лилия Мөхәммәт кызы | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Насыртдинов Олег Рәшит улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт милке белән эш итү идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Парамонов Андрей Иванович | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Сабирҗанов Рэнальд Рәшит улы | «Дәүләт кадастр бәясе куяю үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Столяров Сергей Николаевич | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе башкарма секретаре урынбасары – юридик идарә башлыгы (килешү буенча) |
| Хәмзина Лена Илдар кызы | «Татарстан Республикасы техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |

___________